**Карар № 8**
Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Күлле-Киме авыл җирлеге Советы

“19“ декабрь 2025 ел Күлле-Киме авылы

**Күлле-Киме авыл җирлеге Советының 2019 елның 11 ноябрендәге 110 номерлы карары белән расланган “Күлле-Киме авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

2025 елның 21 апрелендәге 84-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезләмәләрен туктатып тору, Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезләмәләрен гамәлдән чыгару һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын 2025 елда үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» Федераль законның 14 һәм 15 статьялары, Татарстан Республикасы Әтнә районы прокуратурасының 2025 елның 12 декабрендәге 020802-2025/Прп360-25 номерлы протесты нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Күлле-Киме авыл җирлеге Советының 2019 елның 11 ноябрендәге № 110 карары белән расланган (№ 123 10.02.2020 ел, № 130 28.05.2020 , № 5 30.10.2020 , №36 06.12.2021 , №47 16.05.2022, №51 17.08.2022 , №84 27.10.2023 , №97 10.06.2024, №1118 21.04.2025 ел үзгәрешләре белән) "Күлле-Киме авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**1.1. 21 статьяның 3 пунктының икенче, өченче һәм алтынчы абзацларында** «муниципаль-шәхси партнерлык килешүләре ягыннан» дигән сүзләрдән соң «(гавами партнерның, капиталь грантның түләү күләмендә)» сүзләрен өстәргә;

**1.2. 21 статьяның 3 пунктының дүртенче абзацында** «Күрсәтелгән чикләү кагылмый» сүзләрен «Әлеге пунктның икенче һәм өченче абзацларында билгеләнгән чикләүләр кагылмый» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Күлле-Киме авыл җирлеге башлыгы: Гыйниятов И.С.